КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 март г.Казань № 250

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1046 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1046 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 3 май, 259 нчы; 2019 ел, 27 февраль, 128 нче; 2019 ел, 27 июль, 626 нчы, 2019 ел, 30 декабрь, 1236 нчы, 2021 ел, 21 май, 360 нчы, 2022 ел, 10 июнь, 545 нче, 2022 ел, 14 декабрь, 1328 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәэмин итүче чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең

турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Сайлап алуда катнашу өчен, Тәэмин итүче Министрлык тарафыннан расланган форма буенча, сайлап алуны үткәрү турында игълан итүдә күрсәтелгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән түбәндәге документлар кушымтасы белән, Министрлыкка гариза бирә:

бу Тәртипнең 2.10 пункты нигезендә башкарылган грант күләменең исәп-хисабы;consultantplus://offline/ref=8678876990133504E1CE546764C0A812AEDC602212020AA3DBE0453D1947280029BF0F9DAC4514CC1E44467D4C1FBF46B3422F0558902E74668CAA0Dx9hBM

юридик затның гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга үзгәрешләр кертү турында документлар күчермәләре;

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе яки физик затны индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе яисә Юридик затларның (Индивидуаль эшмәкәрләрнең) бердәм дәүләт реестры язмасы бите күчермәсе;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне (грантларны), бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрен дә кире кайтару буенча вакыты чыкканы (җайга салынмаган) һәм Татарстан Республикасы алдындагы акча йөкләмәләре буенча башка вакыты чыккан бурыч булмау турында Тәэмин итүченең җитәкче һәм баш хисапчы (булганда) тарафыннан имзаланган, мөһер белән беркетелгән (мөһере булганда) белешмә (ирекле формада);

Тәэмин итүченең Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә әлеге Тәртипнең 1.4 пунктында күрсәтелгән максатка Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар алмавын раслый торган, Тәэмин итүче җитәкчесе һәм баш хисапчысы (баш хисапчысы булганда) кул куйган һәм Тәэмин итүче мөһере (булган очракта) белән беркетелгән белешмә.

Тәэмин итүче үзгәртеп кору процессында (сайлап алуда катнашучы юридик затка кушылу формасында үзгәртеп корудан тыш), банкротлык процедурасы кертелмәгән ликвидация процессында (сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә сайлап алуда катнашучылар-индивидуаль эшкуарлар индивидуаль эшкуар буларак эшчәнлеген туктатырга тиеш түгеллекне раслый торган Тәэмин итүче җитәкчесе кул куйган, мөһер белән беркетелгән (мөһер булган очракта) белешмә;

«Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар, аны тутыру тәртибе һәм аны электрон формада тапшыру форматы үтәлеше турында белешмә формасын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендщге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү бурычларын салым түләүче (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәү турында салым органының белешмәсе;

бюджет яисә автоном учреждение булган Поставщикның функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органының (дәүләт органының) һәм (яисә) җирле үзидарә органының әлеге Тәртип нигезендә Тәэмин итүче функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Министрлык тарафыннан иректе рәвештә үткәрелә торган сайлап алуда катнашуга ризалыгы;

«Тәэмин итүченең офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, Тәэмин итүче җитәкчесе кул куйган, мөһер белән беркетелгән (мөһер булган очракта) белешмә кәгазен.

Тәэмин итүче гаризада түбәндәгеләрне күрсәтә:

агымдагы елда социаль хезмәтләр күрсәтүне төгәлләү планлаштырыла торган дата;

Тәэмин итүченең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлык тарафыннан сайлап алуда катнашучы, сайлап алуда катнашучы тапшыра торган тәкъдим (заявка) һәм сайлап алуга, шулай ук шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә бәйле башка мәгълүмат турындагы мәгълүматны бастырып чыгару (урнаштыру) белән килешә (физик зат өчен);

Тәэмин итүче әлеге пунктның бишенче, сигезенче, тугызынчы абзацларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Министрлык күрсәтелгән документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Тәэмин итүче тарафыннан тапшырыла торган документларның күчермәләре җитәкченең (Тәэмин итүче вәкаләтәр биргән вәкиле) имзасы һәм Тәэмин итүче мөһере (мөһер булганда) белән таныкланырга тиеш.»;

2.5 пунктта:

беренче абзацта «30» саннарын «10» саннарына алмаштырырга;

бишенче абзацта «30» саннарын «10» саннарына алмаштырырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин